**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"18" ноябрь 2025 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз сум) күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру) эш хәм хезмәтләр өчен түләү));"

2) Бахтияр торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу)

.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.